РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРТАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район,
д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт
тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru

27.03.2018 — № 6

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

Арташ авыл җирлеге территориясендә урнашкан торак пунктларны, икътисад объектларын, предприятиеләрне һәм оешмаларны 2018 елның язгы-җәйге янгын куркынычы чорына әзерләү чаралары турында.

Язгы-җәйге янгын куркынычы янаган чорда торак пунктларның, җирлек территориясендә урнашкан икътисад һәм предприятие һәм оешмаларның янгын куркынычсызлыгын көчәйтү максатларында, Россия Федерациясенең "Янгын куркынычсызлыгы турында" 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 – ФЗ Федераль законнары һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 22 мартындагы 328-П номерлы карары нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге» 2018 елның язгы-җәйге янгын куркынычы чорына район икътисадының төрле рәвешләрендәге һәм торак пунктларындагы объектларны әзерләү чаралары турында

КАРАР БИРӘ :

1. Торак пунктлар янында буалар, аларга һәм табигый су чыганакларына керү юлларын урнаштыруны оештырырга.

2. Терлекчелек фермалары, башка җитештерү объектлары, шулай ук социаль-мәдәни-көнкүреш объектлары территорияләрен җыелган ягулык чүп-чардан арындырырга.

3. Су белән тәэмин итү челтәрен, янгын гидрантларының, сулыкларның, Буаның торышын тикшерергә, су башняларын су алу өчен җайлаштырырга;

4. Тагылма һәм күчмә мотопомпаларны, барлык резерв янгын сүндерү һәм башка техниканы янгын сүндерүгә яраклаштырылган әзерлеккә китерергә;

5. 2018 елның 30 апреленнән 15 маена кадәр торак пунктларда янгын хәлен контрольдә тоту өчен (корыган үләнне, чүп-чар яндыруны булдырмау, учаклар үрчетү һ.б.), җирлекләр территориясендә төнге һәм көндезге сәгатьләрдә профилактик төркемнәр һәм ирекләләр көче белән патрульлек оештырырга.

6. Торак пунктларда минераллаштырылган полосаларны оештыруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

7. Күрсәтелгән чорда янгынга каршы режимны үтәү мәсьәләләре буенча гражданнар җыеннарын оештырырга һәм үткәрергә.

8. Булган янгын техникасының һәм ДПОның сугышчан әзерлеген тикшерергә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Арташ авыл җирлеге башлыгы — А.Р.Әгъләмҗанов